ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.08.2020 г. Заинск № 371

**«2020 - 2022 елларга «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында авыл территорияләрен комплексы үстерү» муниципаль программасын раслау турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында «Авыл территорияләрен комплексы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыру турында» 2020 елның 14 маендагы 387 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, 2020 елның 28 маендагы 07/2-3671 номерлы Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы хаты нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «2020 – 2022 елларга Зәй муниципаль районында авыл территорияләрен комплексы үстерү» муниципаль программасын кушымта нигезендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында (http//zainsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында (http//pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.
4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма**
**комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

2020 елның 28.08.
371 номерлы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитеты
карарына кушымта

# "2020-2022 ЕЛЛАРГА ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА АВЫЛ ТЕРРИТОРИЯЛӘРЕН КОМПЛЕКСЛЫ ҮСТЕРҮ" МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ

## Программаның паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | "2020-2025 елларга Зәй муниципаль районында авыл территорияләрен комплекслы үстерү» муниципаль программасы |
| Программаны эшләү өчен нигез | 1. "Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү турында" 2014 елның 30 сентябрендәге 999 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары<br><br>2. "Авыл территорияләрен комплекслы үстерү" Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында" 2019 елның 31 маендагы 696 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары<br><br>3. "2013-2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу" дәүләт программасын раслау турында" 2013 елның 8 апрелендәге 235 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары<br><br>4. "Татарстан Республикасында "Авыл территорияләрен комплекслы үстерү" Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыру турында" 2020 елның 14 маендагы 387 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары.<br><br>5. «2013 - 2022 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 8 апрелендәге 235 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына |

| | |
|---|---|
| | үзгәрешләр кертү хакында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 25 апрелендәге 330 номерлы карары белән расланган «2013-2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу" ярдәмче программасы<br><br>6. «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак – коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында" 2014 елның 30 апрелендәге 289 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары<br><br>7. «Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында " 1999 елның 21 октябрендәге 2443 номерлы Татарстан Республикасы законы |
| Программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүчеләр | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының торакны исәпкә алу һәм бүлү бүлеге, торак-коммуналь хуҗалык, төзелеш, транспорт, энергетика һәм юл хуҗалыгы бүлеге |
| Программаның максатлары | Авыл территорияләрендә уңайлы тормыш шартлары булдыру, авылга һәм авыл яшәү рәвешенә уңай мөнәсәбәт формалаштыру |
| Программаның бурычлары | Авыл халкының арзанлы һәм уңайлы торакка ихтыяҗларын тәэмин итү;<br>авылны социаль-инженерлык яктан төзекләндерү дәрәҗәсен күтәрү һәм автомобиль юллары белән тәэмин итү;<br>авыл территорияләрендә хезмәт базарын (кадрлар потенциалын) үстерү |
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары | 2020 - 2022 еллар |
| Программаның әһәмиятле максатчан индикаторлары | Авыл җирлегендә яшәүче гражданнар өчен 158 квадрат метр торакны гамәлгә кертү |
| Программаны финанслау | Программаны финанслауның гомуми күләме 3854,9 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән җәлеп итүгә планлаштырыла |

| | |
|---|---|
| күләме | торган акчалар исәбеннән:<br>- федераль бюджет - 1482,4 мең сум;<br>- Татарстан Республикасы бюджеты – 1216,0 мең сум;<br>- Зәй муниципаль районының җирле бюджеты - 27,0 мең сум;<br>- бюджеттан тыш чыганаклар – 1129,5 мең сум. |
| Программаның максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашырудан көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре | Авыл җирлегендә яшәүче 2 гаиләнең торак шартларын яхшырту |

## I. Программаны тормышка ашыру өлкәсе, төп проблемалар, аларның чишелешен бәяләү һәм үсеш фаразлары

Муниципаль район территориясендә хуҗалык эшчәнлегенең төп (иң күбе) җитештерү юнәлешләре булып авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү тора.

2014 елдан Зәй муниципаль районында "2014 - 2017 елларга һәм 2020 елга кадәр чорга авыл территорияләрен тотрыклы үстерү" федераль максатчан программасы турында" 2013 елның 15 июлендәге 598 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган "2014 - 2017 елларга һәм 2020 елга кадәр чорга авыл территорияләрен тотрыклы үстерү" федераль максатчан программасы гамәлгә ашырылды. Әлеге программа кысаларында авыл җирлегендә эшләүче яшь гаиләләрне һәм яшь белгечләрне торак белән тәэмин итү буенча чаралар күрелде. Дәүләт ярдәме алучылар саны 2006 елдан 2016 елның 1 гыйнварына кадәр 120 гаилә тәшкил итте, 8,951 мең квадрат метр күләмендә торак файдалануга тапшырылды.

Авылда яшәү шартларын яхшырту, башка факторлар белән беррәттән, аграр өлкәдә инвестицион активлыкны арттыруга, социаль хәлне яхшыртуга ярдәм итте.

Шул ук вакытта гамәлгә ашырылган чаралар авыл территорияләренең икътисади потенциалын тулысынча һәм нәтиҗәле файдалану һәм авыл халкының тормыш сыйфатын арттыру өчен җитәрлек түгел.

Территорияләрне тотрыклы үстерү чараларын гамәлгә ашыруда дәүләтнең ролен көчәйтү максатчанлыгы түбәндәгеләргә нигезләнгән:

- авыл территорияләрен тотрыклы үстерүнең максатчан куелышының авылда тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрү, икътисадның аграр һәм башка секторларын икътисадый үстерү өчен социаль нигезләр булдыру

өлешендә Россиянең социаль-икътисадый үсеш өстенлекләре белән үзара бәйләнеше;

- аларны хәл итүгә системалы якын килүне таләп итә торган авыл территорияләренең социаль проблемаларының озак сроклы характеры,

- дәүләт ярдәмен җәлеп итүне таләп итә торган авылның проблемалы мәсьәләләрен хәл итүнең югары дәрәҗәдә чыгымлылыгы.

Программа максатларына ирешү авыл территорияләрендә яшәү шартларын яхшыртуга, агросәнәгать комплексында һәм тулаем авыл икътисадында инвестицион активлыкны үстерү өчен уңай шартлар тудыруга ярдәм итәчәк.

Программа максатларына ирешү өчен авыл территорияләрен комплеслы үстерү өлкәсендә куелган бурычларны хәл итү кирәклеген нигезләү түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- авыл җирлегендә хезмәт потенциалын формалаштыруга сизелерлек йогынты ясый торган уңайлы булмаган демографик вәзгыять;

- авыл территорияләрендә социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары белән тәэмин ителешнең түбән дәрәҗәдә булуы;

- авыл җирлегендә торак базары үсеше дәрәҗәсе түбән булу һәм авыл халкы өчен торак шартларын яхшырту проблемаларын хәл итү мөмкинлеге булмау;

- авыл җирлегенең яшәү мохите буларак җәлеп итмәве һәм миграция үсеше, шул исәптән авыл яшьләре арасында да;

- авыл халкының социаль активлыгы түбән дәрәҗәдә булу;

- низкий уровень социальной активности сельского населения;

- җәмгыятьтә авыл территорияләрен үстерү перспективаларына уңай караш булмау.

Программа Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Авыл территорияләрен комплексы үстерү" Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында" 2019 елның 31 маендагы 696 номерлы карары белән расланган "Авыл территорияләрен комплексы үстерү" Россия Федерациясе дәүләт программасы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 25 апрелендәге 330 номерлы карары белән расланган «Авыл территорияләрен комплексы үстерү» ярдәмче программасы нигезендә эшләнде.

## II. Программаның максатлары, бурычлары һәм төп көтелгән ахыргы нәтиҗәләре, аны тормышка ашыру сроклары

Программаның максаты - авыл территорияләрендә яшәү өчен уңайлы шартлар тудыру, авылга һәм авыл яшәү рәвешенә уңай мөнәсәбәт формалаштыру.

Максатларга ирешү өчен авыл халкының уңайлы торакка булган ихтыяҗларын канәгатьләндерү, авылның социаль-инженерлык төзеклеге дәрәҗәсен күтәрү һәм автомобиль юллары белән тәэмин итү бурычларын хәл итәргә кирәк.

Булган потенциалны нәтиҗәле файдалану, дәүләт ярдәме һәм бюджеттан тыш инвестицияләрне җәлеп итү куелган максатларга ирешергә мөмкинлек бирә.

Авыл җирлегендә яшәүче гражданнар өчен 158 квадрат метр торакны гамәлгә кертү. Авыл җирлегендә яшәүче 2 гаиләнең торак шартларын яхшырту.

Программаны гамәлгә ашыру срогы: 2020 - 2022 еллар.

## III. Программаның төп чараларына характеристика

Программа түбәндәге чараларны үз эченә ала:

- авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту һәм торакка наем шартнамәсе буенча бирелгән торак төзү;

- авыл җирендә урнашкан торак пунктларны, социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектларын комплекслы төзекләндерү, шул исәптән авыл территорияләрен төзекләндерү буенча чараларны гамәлгә ашыру, авыл территорияләрендә газификация, су белән тәэмин итүне үстерү, авыл территорияләрендә компактлы торак төзелеше өчен мәйданчыкларны комплекслы төзекләндерү проектларын гамәлгә ашыру, компактлы торак төзелеше өчен авыл территорияләрендә урнашкан инженерлык инфраструктурасы объектларын төзекләндерү һәм мәйданчыкларны төзекләндерү проектларын тормышка ашыру, гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәреннән авыл территорияләрендә урнашкан авыл торак пунктларының иҗтимагый әһәмиятле объектларына, продукция житештерү һәм эшкәртү объектларына алып бара торган каты өслекле автомобиль юллары челтәрен үстерү, авыл территорияләрен (авыл агломерацияләрен) комплекслы үстерү проектларын гамәлгә ашыру, федераль дәүләт мәгариф оешмаларында югары белем алучыларга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан укучылар белән төзелгән килешүләр буенча чыгымнарның 30 процентын кайтару, федераль дәүләт мәгариф оешмаларында югары белем алучыларга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан студентларның хезмәт хакы һәм яшәү белән бәйле чыгымнарының 30 процентын кайтару.

Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту мөмкинлеген арттыруны түбәндәге юллар белән гамәлгә ашыру күздә тотыла:

- авыл территорияләрендә торак төзүгә һәм сатып алуга федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты һәм муниципаль районнарның җирле бюджеты акчалары исәбеннән социаль түләүләр бирү;

- федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты һәм муниципаль районнарның җирле бюджеты акчалары исәбеннән алга таба сатып алу хокукы белән наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак төзелешен финанслашу;

- торак төзегәндә (сатып алганда) ташламалы ипотека торак кредиты һәм ана (гаилә) капиталы механизмнарын куллану;

- торак өлкәсендә инвестицион активлыкны стимуллаштыру нигезендә авыл җирендә торак төзелеше күләмен арттыру.

Авыл җирлегендә урнашкан торак пунктларны, социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектларын комплекслы төзекләндерү чараларын гамәлгә

ашыру түбәндәге юнәлешләр буенча гамәлгә ашырыла:

- авыл территорияләрен төзекләндерү;
- авыл территорияләрендә газлаштыруны үстерү;
- авыл территорияләрендә су белән тәэмин итүне үстерү;
- авыл территорияләрендә компактлы торак төзелеше өчен мәйданчыкларны комплекслы төзекләндерү проектларын тормышка ашыру;
- компактлы торак төзелеше өчен авыл территорияләрендә урнашкан инженерлык инфраструктурасы объектларын төзекләндерү һәм мәйданчыкларны төзекләндерү проектларын тормышка ашыру;
- гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәреннән авыл территорияләрендә урнашкан авыл торак пунктларының иҗтимагый әһәмиятле объектларына, җитештерү һәм эшкәртү объектларына алып баручы каты өслекле гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәрен үстерү;
- авыл территорияләрен (авыл агломерацияләрен) комплекслы үстерү проектларын гамәлгә ашыру.

Комплекслы төзелеш проектлары агросәнәгать комплексының тизләтелгән үсеше барган урыннарда, шул исәптән инвестицион проектлар гамәлгә ашырыла торган территориядә агросәнәгать производствосының заманча технологияләре өлкәсендә белемле яшьләрне җәлеп итеп тормышка ашырылырга тиеш.

Авыл территорияләрендә урнашкан торак пунктларның социаль һәм инженерлык инфраструктурасы объектларын комплекслы төзекләндерүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү һәм бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Кагыйдәләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

## IV. Программаны ресурслар белән тәэмин итү һәм аны нигезләү

Программаны финанслауның гомуми күләме 93960 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән федераль бюджет акчаларын җәлеп итүгә планлаштырыла торган акчалар исәбеннән - 38147,76 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән - 27624,24 мең сум, районның җирле бюджеты акчалары исәбеннән - 657,72 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклар исәбеннән - 27530,28 мең сум.

## V. Программаны гамәлгә ашыру куркынычын анализлау һәм әлеге куркынычларга идарә чаралары тасвирламасы

Программаны гамәлгә ашыру кайбер куркынычлар белән бәйле, аларның төп өлешләре түбәндәгеләр:

- федераль законнар үзгәрү;
- программаны финанс белән тәэмин итүнең төрле чыганакларыннан финанслауның булмавы яисә тулысынча финансланмавы.

Программаны гамәлгә ашыру куркынычы белән идарә итү "Авыл территорияләрен комплекслы үстерү" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Авыл территорияләрен комплекслы үстерү" Россия Федерациясе дәүләт

программасын раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2019 елның 31 маендагы 696 номерлы карары белән расланган "Авыл территорияләрен комплекслы үстерү" Россия Федерациясе дәүләт программасында каралган чараларны куллану нигезендә гамәлгә ашырылачак.

Кушымта

**“Авыл территорияләрен комплексле үстерү" программасын тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү**

| Бурычның исеме | Чараның исеме | Финанслау чыганагы | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | Барысы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| Авыл халкын һәркем өчен мөмкин булган һәм уңайлы торак белән тәэмин итү | Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту | федераль бюджет | 765,9 | 140,5 | 576,0 | 1482,4 |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | 554,6 | 129,7 | 531,7 | 1216 |
| | | муниципаль районнарның җирле бюджеты | 13,2 | 2,7 | 11,1 | 27 |
| | | бюджеттан тыш чыганаклар | 552,7 | 113,1 | 463,7 | 1129,5 |
| Барысы | | | 1886,4 | 386 | 1582,5 | 3854,9 |